Раслыйм:

«Сәләт» ТТЯФ
генераль директоры

Э.Р. Насибуллина

«23» май 2025 г.

# НИГЕЗЛӘМӘ

## «Остаз» проектын үткәрү турында

### 1. Гомуми нигезләмәләр

«Остаз» проекты (алга таба – Проект) традицион рәвештә Биләр дәүләт тарихи – археологик музей-тыюлыгы территориясендә Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Нургали улы Миңнеханов кушуы буенча үткәрелә торган «Сәләт» XIV Халыкара яшьләр уку-укыту форумының (алга таба – Форум) «Сәләт Биләр Форум» сменасының бер өлеше булып тора.

Форум катнашучылары өчен экспертлардан уникаль белем һәм тәкъдимнәр алу, белем бирү һәм мәдәни программаларда катнашу, үзләрен күрсәтү аша үз компетенцияләрен үстереп, башка катнашучылар һәм экспертлар белән һөнәри, мәдәни элемтәләр урнаштыра, тәҗрибә уртаклаша һәм алга таба үсешкә этәргеч ала торган мөмкинлекләр тудырылган мохит булдыруга омтыла.

Форум «Сәләт» (ТАЛАНТ) Татарстан төбәк яшьләр фонды тарафыннан Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы белән берлектә оештырыла.

«Остаз» проектын уздыру өчен оештыручылар һәм чакырылган экспертлар арасыннан оештыру комитеты (алга таба – Оештыру комитеты) төзелә, ул аны әзерләүнең һәм уздыруның һәр этабын гамәлгә ашыру өчен җавап бирә.

### 2. Проектның максаты

«Остаз» проектының төп максаты – мәгариф өлкәсендә педагогларны һәм идарәчеләрне һөнәри һәм шәхси үстерү, республика мәгарифендәге актуаль мәсьәләләрне чишү өчен инновацион юллар эзләү, мәгариф өлкәсендә татар телен үстерү һәм тәҗрибә уртаклашу мәйданчыгын булдыру.

## 1. Проектның үткәрелү этаплары

Проект 3 этапта уздырылачак:

1 нче этап – «Катнашучылардан гаризалар кабул итү»: **2025 елның 28 нче маеннан 20 нче июненә кадәр.** Гаризалар http://biler.selet.biz/ru сайтында билгеләнгән формада кабул ителә. Гаризада видеоязма булырга тиеш.

2 нче этап – «Читтән торып сайлап алу этабы»: **2025 елның 21 нче июненнән 26 нчы июненә кадәр.** Проектта катнашучыларны конкурс буенча сайлап алу эксперт комиссиясе тарафыннан гариза, анда күрсәтелгән казанышлар һәм видеоматериаллар нигезендә үткәрелә.

3 нче этап – «Форумда катнашу этабы»: **2025 елның 9 нчы июленнән 12 нче июленә кадәр.** Экспертлардан остаханәләр, тренинглар, проект төркемнәрендә эшләү, түгәрәк өстәл, интеллектуаль һәм иҗади чараларны үз эченә алган «Остаз» проектының мәгариф һәм мәдәни программаларында катнашу.

## 2. Форумда катнашу шартлары

4.1. Проектта Казан шәһәре, Татарстан Республикасы һәм күрше төбәкләрдән гомуми белем бирү оешмаларының педагоглары, укыту, тәрбия эше һәм милли мәсьәләләр буенча директор урынбасарлары, педагогик юнәлешләрдәге югары һәм урта һөнәри белем бирү мәгариф оешмаларының өлкән курс студентлары катнашалар.

4.2. Конкурста катнашу өчен сайтта билгеләнгән үрнәктәге гариза анкетасын дөрес һәм тулы мәгълүмат биреп тутырырга кирәк http://biler.selet.biz. Катнашучылар гаризаларны анализлау нигезендә сайлап алына.

4.2.1. Конкурста катнашу өчен «Мин – «Остаз» проекты катнашучысы» темасына 2 минуттан да артык булмаган үз-үзеңне тәкъдим итү видеоязмасын беркетергә кирәк. Видеоязмалар татар телендә яки рус телендә кабул ителә; татар теле өстенлекле.

Видеоязманы Яндекс.диск яки башка мәгълүмати ресурслар саклагычында урнаштырырга, сылтамасын гариза анкетасында күрсәтергә кирәк. Видеоматериаллар проектка катнашучыларны сайлап алу барышында исәпкә алыначак. Сайлап алуга гаризалар видеога керү мөмкинлеге ачык булган сылтама белән генә кабул ителәчәк.

4.2.2. Конкурста катнашу өчен портфолио беркетергә кирәк. Портфолио Сәләт проектларында, шәһәр, район яки югарырак дәрәҗәдәге рәсми чараларда катнашкан өчен алынган бүләкләрне (дипломнар, сертификатлар, грамоталар, таныклыклар, рәхмәт

хатлары һ.б.) үз эченә ала. Гаризада катнашучының гариза бирү датасына кадәр өч ел алдан алынган бүләкләүләре кабул ителә. Бирелә торган казанышларның максималь саны - 10.

4.3. Проектта катнашу өчен гариза җибәреп, катнашучылар үзләренең шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык бирәләр.

4.4. Проектта катнашучыларны гаризалар буенча эксперт комиссиясе сайлап ала.

4.5. Проектта катнашу этабында (9 июльдән 12 июльгә кадәр) электрон почтага рәсми чакыру алучылар гына катнаша ала. Катнашу этабында узучылар исемлеге гаризалар кабул итү тәмамланганнан соң 7 көн эчендә http://biler.selet.biz сайтында урнаштырыла.

4.6. Катнашучылар форумга бару пунктына (Казан шәһәре) мөстәкыйль рәвештә киләләр. Форумга оештырылган җыелу һәм җибәрелүнең төгәл урыны һәм вакыты өстәмә рәвештә хәбәр ителәчәк.

4.7. Катнашу этабында «Остаз» проектының һәр катнашучысының үзе белән түбәндәге документлар булырга тиеш:

- РФ паспортының күчермәсе (2, 3, 5 б.);

- мәҗбүри медицина иминияте полисы күчермәсе;

- медицина белешмәсе китабы түбәндәге штамплар белән: табиб-терапевт; табиб-психиатр; табиб-нарколог; табиб-невролог; акушер-гинеколог (хатын-кызларга); табиб-оториноларинголог; табиб-стоматолог; табиб-дерматолог; флюорография; канны сифилиска тикшерү; гонореяга мазокны тикшерү; гельминтозлар (корт йомыркасына кал анализы һәм энтеробиозга соскоб) һәм эчәк протозоозлары (лямблий цисталарына тикшерену); эчәк инфекцияләрен кузгатучыларны йөртүгә тикшерену; тифка канны серологик тикшерү; дифтерия һәм столбнякка каршы прививкалар (соңгы ревакцинациядән соң һәр 10 елдан артмаска тиеш), 18 яшьтән 55 яшькә кадәрге өлкәннәргә вируслы гепатитка каршы прививкалар (вакцинация һәм ревакцинация), 55 яшькә кадәрге кызамыкка каршы (шул исәптән), кызылчага каршы (вакцинация һәм ревакцинация турында белешмәләр).

4.8. Проект оештыру кертемнәрсез үткәрелә.

4.9. Проектта катнашучылар туклану, чатырларда урнаштыру, шулай ук оешма продукциясе белән тәэмин ителәчәк.

4.10. Проектның мәгариф һәм мәдәни программасында катнашу барлык катнашучылар өчен дә мәҗбүри.

4.11. Проект нәтиҗәсендә катнашучыларга программа узу турында академик сәгатьләр саны күрсәтелгән сертификат бирелә.

4.12. Катнашучылар әлеге Нигезләмәнең барлык шартларын да үтәргә вәгъдә итәләр. Катнашучыларның үз-үзләрен тотуда этик нормаларны бозуы «Остаз» оештыру комитеты

яки форумның башкарма дирекциясе кабул иткән карар нигезендә проектта теләсә кайсы этапта катнашу мөмкинлегеннән мәхрүм итүгә китерә.

### 3. «Остаз» проектына катнашучыларны сайлап алу критерийлары

Катнашучыларны сайлап алу түбәндәге критерийлар буенча гаризаларны анализлау нигезендә үткәрелә:

**5.1. Һөнәри эшчәнлек**

Мәгариф өлкәсендә эш тәҗрибәсе

Һөнәри эшчәнлектә казанышлар булу

Кыйммәтләргә юнәлдерелгән алымны куллану

Заманча технологияләр һәм методикалар куллану

**5.2. Сәләттәге эшчәнлек**

Сәләт проектларында катнашу тәҗрибәсе

Сәләт проектларында казанышлар булу

**5.3. Татар телен белү**

Татар телен белү дәрәҗәсе. Өстенлек татар телен белгән һәм һөнәри эшчәнлектә татар телен кулланырга сәләтле катнашучыларга бирелә

**5.4. Фәнни-методик эшчәнлек**

Фәнни басмалар булу

Методик эшләнмәләр булу

Фәнни һәм методик конференцияләрдә катнашу

**5.5. Кыйммәтләр ориентирлары**

Сәләт берләшмәсенең кыйммәтләре белән килешү (аңлау һәм кабул итү)

**5.6. Шәхси характеристикалар**

Дөрес шәхесара аралашу культурасы

Шәхси һәм һөнәри үсешкә сәләтлелек һәм әзерлек

Һөнәри сыгылмалылык һәм җайлашучанлык

**5.7. Проектта катнашуга мотивация**

Проектта актив һәм аңлы рәвештә катнашуга әзерлек

Проектта алынган тәҗрибәне һөнәри эшчәнлектә куллануга әзерлек

### 4. Проектның Оештыру комитеты

6.1. Оештыру комитеты проектны әзерләү һәм уздыру өчен җаваплы. Оештыру комитеты составы «Сәләт» Халыкара яшьләр мәгариф форумының оештыру комитеты

әгъзалары, чакырылган экспертлардан төзелә һәм «Сәләт» ТРМФ генераль директоры тарафыннан раслана.

6.2. Оештыру комитеты проектны әзерләү һәм уздыру буенча бөтен оператив эшне башкара:

- проектның барлык этапларын административ тәэмин итә;
- проект программасын эшли һәм раслый;
- үткәрү вакытын һәм урынын билгели;
- эксперт комиссиясе составын билгели;
- әлеге нигезләмәгә өстәмәләр һәм үзгәрешләр кертергә хокуклы («Сәләт»ТРМФ генераль директоры белән килешеп).

6.3. Проектны оештыру комитетының контакт мәгълүматы:

- тел.: +7 (987) 405-18-94
- электрон почта адресы: habil.sahabiev@selet.biz